**СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул.Молодежная, д.73,
с. Тубылгы тау,423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Яшьләр урамы, 73
Тубылгы Тау авылы,423181

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2016 елның 17 нче феврале № 9 - 25

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге Советының 2015 елның 10 мартындагы 40-89 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» Тубылгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 3 ноябрендәге 89 – ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке белән чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109 – ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге Советының 2015 елның 10 мартындагы 40-89 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» Тубылгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 5 статьясындагы 1 өлеше 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "муниципаль район территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итү, муниципаль районның рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;»;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 50 статьясындагы 1 өлеше 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итә, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыра;»;

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Тубылгы Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 71 статьясындагы 9 пунктына түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә: «хокукый акт текстын яисә хокукый акт проектын Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштыру;

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Тубылгы Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 85 статьясының атамасына «һәм башка муниципаль контроль төрләре» сүзләрен өстәргә;

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Тубылгы Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 85 статьясына түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

- Муниципаль контрольнең башка төрләре:

- муниципаль торак контроле;

- муниципаль җир контроле;

- муниципаль район территориясендә ваклап сату базарында товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) эшчәнлеген оештыруны һәм тормышка ашыруны контрольдә тоту;

- алкогольле продукцияне ваклап сату өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшереп тору;

- товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актлар үтәлешен үз компетенциясе чикләрендә тикшереп тору;

- энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча чараларны координацияләү һәм аларны муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан үткәрүне контрольдә тоту;

- гомуми таралган файдалы казылмалар чыгарганда җир асты байлыкларыннан файдалануны һәм аларны саклауны, шулай ук файдалы казылмалар чыгару белән бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзүне контрольдә тоту;

- муниципаль район территориясендә Җәзаларны үтәтүче учреждениеләр һәм тикшерү изоляторлары эшчәнлеген Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә контрольдә тоту.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы" нда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Тубылгы Тау авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча: ТР, Яна Чишмэ районы, Тубылгы Тау авылы, Яшьләр урамы, 73 нче йорт буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (бастырырга).

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгы Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын дәүләт теркәвенә алу өчен яңа редакциядә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы территорияләрен законлылык, җирдән файдалану һәм төзекләндерү буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы

Ф.Ф. Исмәгыйлев